РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ БОЛЬШЕМЕШСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ТЮЛЯЧИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

Школьная ул., д. 1, с. Большая Меша, 422088
тел.: (84360) 55-1-45,
E-mail: Bms.Tul@tatar.ru

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ОЛЫ МИШӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕНЕҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Мәктәп ур., 1 нче йорт, Олы Мишә авылы, 422088
тел.: (84360) 55-1-45,
E-mail: Bms.Tul@tatar.ru

ОКПО 94318205 ОГРН 1061675010980 ИНН/КПП 1619004468/161901001

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**№ 5** **«01» февраль 2023 ел.**

**Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Олы Мишә авыл җирлегендә 2023 елга җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр хакын раслау турында**

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча Дәүләт комитетының 2023 елның 20 гыйнварындагы №ЛХ-28/269/2023 хатын карап, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Җирләү һәм күмү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2023 елның 30.01.2023 елгы №119 номерлы «2023 елда түләүләрне, пособиеләрне һәм компенсацияләрне индексацияләү коэффициентын раслау турында» карары, «Татарстан Республикасында җирләү һәм күмү эше турында» Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары хакында» 2007 елның 18 маендагы 196 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә, Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Олы Мишә авыл җирлеге Башкарма комитеты,

**КАРАР БИРӘ:**

1. Теләче муниципаль районы Олы Мишә авыл җирлегендә гарантияләнгән күмү хезмәтләре исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр бәясен 2023 елның 1 гыйнварыннан 1 номерлы һәм 2 номерлы кушымталар нигезендә 7793,48 сум күләмендә билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.
2. Әлеге карар гамәлдәге законнар нигезендә үз көченә керә.

Ф.Б.Җамалетдинов

Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Олы Мишә авыл җирлеге башкарма комитетының «01» февраль 2023 № 5 карарына 1 номерлы кушымта

Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Олы Мишә авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүләр исемлегенең 2023 елның 1 февраленнән гарантияләнгән бәясе

| Хезмәт күрсәтү атамасы | Хезмәт күрсәтү бәясе (сумнарда) |
| --- | --- |
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 151,62 |
| 2. Күмү өчен кирәкле табутны һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 3245,26 |
| 3. Мәрхүмнең гәүдәсен (калдыкларын) зиратка илтү | 927,34 |
| 4. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 3469,26 |
| **БАРЛЫГЫ:** | **7793,48** |

Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Олы Мишә авыл җирлеге башкарма комитетының «01» февраль 2023 № 5 карарына 2 номерлы кушымта

Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Олы Мишә авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүләр исемлегенең 2023 елның 1 февраленнән гарантияләнгән бәясе

| Хезмәт күрсәтү атамасы | Хезмәт күрсәтү бәясе (сумда) |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 151,62 |
| 2. Тәнне киендерү | |
| 3. Күмү өчен кирәкле табутны һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 3245,26 |
| 4. Мәрхүмнең гәүдәсен (калдыкларын) зиратка илтү | 927,34 |
| 5. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 3469,26 |
| **БАРЛЫГЫ:** | **7793,48** |

Олы Мишә авыл җирлеге башлыгы: Ф.Б.Җамалетдинов